| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.10.2021 Казан шәһәре № 594/2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 10 июлендәге 262/2020 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын актуальләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 10 июлендәге 262/2020 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 22 декабрендәге 718/2020 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 2021 елның
«16» 11. 594/2021
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 10 июлендәге 262/2020 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектәге 1.3 пунктның 1.3.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.2. Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: 221-82-42, 221-82-55, 221-82-39, 221-82-44, 221-82-86.

Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – Дәүләт комитетының рәсми сайты) рәсми сайты адресы: http://kt.tatarstan.ru, Дәүләт комитетының электрон почта адресы: kt@tatar.ru.

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен җаваплы булган Дәүләт комитеты структур бүлекчәсе хезмәткәренең электрон почта адресы: Elza.Kubasheva@tatar.ru.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү (алга таба – тарифлар билгеләү)

2.2. Башкарма хакимият органы исеме.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау.

Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү йә бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдимне караудан баш тарту һәм тапшырылган документларны һәм материалларны кире кайтару хакында карар.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Бәяләр (тарифлар) билгеләнә торган чираттагы хисап чоры башланачак чор алдыннан килгән елның 20 декабреннән соңга калмыйча.

2.4.2. Элек үзләренә карата бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешмалар өчен агымдагы җайга салу чорына бәяләр (тарифлар) билгеләнгән, шулай ук җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган, элек үзләренә карата бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган аерым оешмалар тарафыннан хәл ителүче аерым төрләренә бәяләр (тарифлар) билгеләнгән очракларда – гариза кергән көннән башлап 30 календарь көне. Дәүләт комитеты карары буенча бу срок 30 календарь көнгә озайтылырга мөмкин.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.4. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап биш эш көне эчендә, ләкин чираттагы җайга салу чорына кадәрге елның 21 декабреннән соңга калмыйча, Дәүләт комитеты әлеге карарның таныкланган күчермәсен, беркетмәне (беркетмәдән өземтәне) теркәп, әлеге карарда үзенә карата бәяләр (тарифлар) билгеләнгән җайга салынулы оешма адресына җибәрә.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдимне караудан баш тарту, мөрәҗәгать итүче тапшырган документларны һәм материалларны кире кайтарып, бәяләр (тарифлар) билгеләү турында гариза теркәлгән вакыттан башлап 10 эш көне узганчы гамәлгә ашырыла.

2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе.

2.5.1. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдим оешманың бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы гаризасыннан (әлеге Регламентка 1 нче кушымта) һәм кирәкле нигезләү материалларыннан тора.

Бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы гаризага түбәндәге документлар һәм материаллар теркәлә:

а) эшчәнлекнең җайга салына торган төрен гамәлгә ашырганда кулланыла торган, үзләренә карата хокуклар Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән (мондый хокуклар әлеге реестрда теркәлгән очракта, әлеге биналар, төзелмәләр, корылмалар, җир кишәрлекләре турындагы белешмәләр тапшырыла) күчемсез объектларга (биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, җир кишәрлекләренә) карата милекчелек хокукын, башка төрле законлы хокукны раслый торган хокук билгеләүче документларның күчермәләре (граждани-хокукый килешүләрнең, концессия килешүләренең күчермәләре, юридик зат үзгәртеп корылган очракта, – тапшыру актларының күчермәләре);

г) алдагы җайга салуның алдагы хисап чорына һәм соңгы хисап датасы өчен бухгалтерлык һәм статистик хисаплылык күчермәләре;

в) җылылык энергиясе (егәрлеге), җылылык китерү матдәсе, челтәрләр буенча тапшыруга кайнар су чыгымнары (югалтулар) күләмен, шул исәптән «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – «Җылылык белән тәэмин итү турында» федераль закон) нигезендә төзелгән килешүләргә ярашлы рәвештә, якларның килешүе белән

билгеләнгән бәяләр буенча җылылык энергиясен (егәрлеген), җылылык китерү матдәсен китертү күләмен нигезләп, төрләр буенча дифференциацияләп, җылылык энергиясен (егәрлеген), җылылык китерү матдәсен нәтиҗәле җибәрү исәпләмәсе. Ресурсларны нәтиҗәле җибәрү исәпләмәсендә халыкка һәм аңа тиңләштерелгән кулланучылар категорияләренә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә товарларга һәм хезмәтләр күрсәтүгә җайга салына торган бәяләр (тарифлар) буенча җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен сатыла торган җылылык энергиясе (егәрлеге), җылылык китерү матдәсе күләме чагылдырыла;

г) җайга салуның алдагы хисап чорына һәм хисап чорына кулланыла торган ягулыкның структурасы һәм бәяләре, шулай ук аның калориялелеге һәм аны китертү (ташу) хакы турындагы белешмәләр;

д) җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган эшчәнлектән чыгымнар һәм кирәкле тулай табыш исәпләмәсе, беренчел белешмәләргә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр (алга таба – методик күрсәтмәләр) нигезендә әзерләнгән икътисадый нигезләү (кулланыла торган индексларны, нормаларны һәм исәпләмә нормативларын, тарифларны җайга салу буенча тәкъдим ителә торган методны, озак сроклы җайга салу буенча тәкъдим ителә торган билгеләрне, җылылык белән тәэмин итү схемасында (ул расланган очракта) кабул ителгән чагыштырма үзгәрүчән чыгымнарны күрсәтеп) теркәп;

е) бәяләр (тарифлар) исәпләмәсе;

ж) билгеләнгән тәртиптә расланган инвестиция программасы күчермәсе (яки инвестиция программасы проекты), заем капиталын турыдан-туры финанслау һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле акчаларга булган ихтыяҗны нигезләп һәм, әгәр инвестиция программасын раслау «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы федераль законда каралган булса, инвестиция программасын финанслау чыганакларын күрсәтеп;

з) җайга салуның алдагы хисап чорында керми кала торган яки өстәмә алынган, рәсми статистик һәм бухгалтерлык хисаплылыгы яисә җайга салынулы оешмаларның хуҗалык эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре нигезендә, шулай ук сатулар уздыру нәтиҗәсендә төзелгән килешүләр нигезендә ачыкланган керемнәр исәпләмәсе (әгәр тарифларның җайга салу методында башкача каралмаган булса);

и) мөрәҗәгать итүче тарафыннан сатулар үткәрүне раслый торган документларның күчермәләре (сатулар үткәрү турында нигезләмә, белдерү, документлар, сатулар үткәрү барышында төзелә торган беркетмәләр);

к) җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешүләр (шулай ук җылылык белән тәэмин итү килешүләренең, һәм (яки) җылылык энергиясен, җылылык китерү матдәсен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтү турындагы килешүләрнең, һәм (яки) җылылык энергиясен (егәрлеген) һәм (яки) җылылык китерү матдәсен китертү килешүләренең, һәм (яки) резервлы җылылык егәрлеген саклап тоту буенча хезмәтләр күрсәтү килешүләренең, һәм (яки) тоташтыру турындагы килешүләрнең) исемлеге, анда килешү төзелгән зат турында, килешү предметы, килешүне төзү датасы, килешүнең гамәлдә булу срогы, килешү

буенча гамәлгә ашырыла торган товарлар (эшләр, хезмәтләр күрсәтү) күләме, кулланыла торган җылылык китерү матдәсенең төре һәм параметрлары турында мәгълүматлар чагылдырылырга тиеш.

л) ышаныч кәгазеннән башка гына оешма исеменнән эш итәргә хокуклы затны билгеләү турындагы документ күчермәсе;

м) дәүләт яки муниципаль милектәге җылылык белән тәэмин итү объектларына карата концессия килешүе буенча яклар килешүе нигезендә яки, җирлекне, шәһәр округын җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарына керткәнчегә кадәр, әлеге объектларның аренда килешүе нигезендә җитештерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә), шул исәптән электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында да, ике ставкалы тариф сайлау турында гариза, әлеге концессия килешүендәге (аренда килешүендәге) якларның җитештерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә), шул исәптән электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында да, тариф төрен бер ставкалыдан икен ставкалы тарифка үзгәртүгә ризалыгын раслый торган документларны теркәп;

н) оешманың тутырылган паспорты (әлеге Регламентка 2 нче кушымта).

Бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы гариза җайга салынулы оешманың җитәкчесе яки башка вәкаләтле заты тарафыннан имзалана, җайга салынулы оешманың мөһере (булган очракта) белән таныклана һәм теркәлә торган документлар һәм материаллар исемлеген үз эченә ала.

Бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы эшне ачу өчен документлар һәм материалларның әлеге исемлеге тулы булып тора.

Җайга салынулы оешма инициативасы буенча, күрсәтелгән документлардан һәм материаллардан тыш, бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы эшне карау өчен мөһим булган башка документлар һәм материаллар, шулай ук эксперт бәяләмәсе дә тапшырыла ала.

2.5.2. Моңа кадәр үзенә карата бәяләргә (тарифларга) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешма өчен бәяләр (тарифлар) билгеләнгәндә, шулай ук җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә аерым оешмалар гамәлгә ашыра торган җайга салынулы эшчәнлекнең аерым төрләренә тарифлар билгеләнгән очракта, элегрәк аларга карата бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмый торган булса, әлеге Регламентның 2.5.1 пунктының «и» һәм «к» пунктчаларында күрсәтелгән документлар тапшырылмый.

2.5.3. Юридик затларны берләштерү яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп кору нәтиҗәсендә барлыкка килгән оешма тарафыннан шулай ук мондый оешманың дәүләт теркәвенә алу датасына бухгалтерлык хисабы тапшырыла.

2.5.4. Документларның күчермәләрен, күчермәләрне билгеләнгән тәртиптә раслау шарты белән, аларның төп нөсхәләре урынына тапшыру рөхсәт ителә.

2.5.5. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.6. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы аша.

Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.5.7. Җайга салынулы оешма, чираттагы җайга салу чорына кадәр, елның 1 маена кадәр, тарифларны җайга салу органына тарифлар билгеләү турында тәкъдим кертә.

2.5.8. Агымдагы елга тарифлар билгеләнгән очракта, элек тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган оешма өчен тарифлар билгеләү турындагы тәкъдим мондый оешма тарафыннан агымдагы елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны тапшыру тәртибе

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка органнар карамагында булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар каралмаган.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләренең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим тапшыру срокларын үтәмәү дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе булып тора.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яисә башка түләү алынмый.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри күрсәтелергә тиешле хезмәтләр юк.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри күрсәтелергә тиешле хезмәтләр юк.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты.

Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (аңа хезмәт күрсәтелүне) көтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да.

Гариза тапшырылган көнне.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим тапшыру датасы:

а) бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим турыдан-туры Дәүләт комитетына тапшырылган очракта – бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы гариза теркәлгән дата;

б) бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим почта (курьер) элемтәсе белән җибәрелгән очракта – почта юлламасын элемтә оешмасына тапшыру турында почта юлламасында штемпель белән расланган дата;

в) бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим электрон рәвештә тапшырган очракта – бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим Дәүләт комитетының электрон документ әйләнеше системасында теркәлгән дата.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр.

2.14.1. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда күрсәтелә:

һаваны кондиционерлау системасы белән;

янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;

документларны рәсмиләштерү өчен мебель белән;

мәгълүмат стенды белән.

2.14.2. Инвалидларга һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре чикләнгән затларга дәүләт хезмәтләрен күрсәтү яшәү урыны буенча яисә видеоэлемтә аша, интернет аша дистанцион режимда гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы мәгълүмат Дәүләт комитетына төп керү юлы янында һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләре бүлеге аша керү урынында, Мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән

инвалидларның да чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, мәгълүмат такталарында урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, объектлардан һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу шартлары;

объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль рәвештә яки хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

объектларга керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга объектларда ярдәм күрсәтү;

инвалидларның объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

хезмәттән файдалану өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны кабатлап күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене, шулай ук ишарә телен белә торган башка затны кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар өчен үтемле формада хезмәт күрсәтү тәртибен аңлатуга, аны күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүгә, инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе белән таныштуыруга, хезмәттән файдалану өчен кирәкле гамәлләр эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;

инвалидларның яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеге;

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәттән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү.

2.14.4. 2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте

күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы.

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең гамәлләренә прецедентлар (нигезләнгән шикаятьләр) булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгечләре белән шәхси мөрәҗәгать иткәндә үзара бәйләнешкә керү саны икедән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

Дәүләт комитеты бинасының җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында Дәүләт комитеты мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;

гаризаны Интернет челтәрендә Дәүләт комитетының мәгълүмат ресурслары ярдәмендә электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша гариза тапшыру һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу мөмкинлеге (мондый мөмкинлек тудырылганнан соң).

2.15.3. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ) аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелми.

2.15.4. Мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге юк.

2.15.5. Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган гаризаны Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша электрон формада тапшыру мөмкинлеге бар (алга таба – Интернет-кабул итү системасы).

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru) аша электрон документ формасында гариза бирү мөмкинлеге булдырылганнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон рәвештә бирелә.»;

3 нче бүлектә:

Аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар кабул итү:

3.6.1. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдимгә экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар проектын әзерләү өчен җаваплы бүлек хезмәткәре бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар проектын, аңлатма язуын әзерли һәм алга таба Эшче тариф комиссиясе утырышында карау өчен бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы, рәис урынбасары белән килештерә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләр (тарифлар) билгеләү турында әзерләнгән карар проекты, аңлатма язуы.

3.6.2. Тарифлар билгеләү турында карар проекты Дәүләт комитетының Эшче тариф комиссиясе утырышында «Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карарлар кабул итү регламентын һәм тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының башка карарларын кабул итү регламентын раслау турында» 2021 елның 22 июлендәге 450/2021 номерлы боерыгында каралган тәртиптә һәм срокларда карала  (алга таба – Карарлар кабул итү регламенты).

Дәүләт комитеты һәм җайга салына торган оешма, дәүләт хакимиятенең мәнфәгатьле башкарма органы, җирле үзидарә органы арасында карар проекты буенча каршылыклар булмаса, килештерү кәгазенә имза салына, һәм карар проекты Дәүләт комитеты идарәсе утырышына чыгарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Эшче тариф комиссиясе беркетмәсе, имзаланган килештерү кәгазе һәм бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар проекты.

Карар проекты буенча каршылыклар булса, җайга салына торган оешма, дәүләт хакимиятенең мәнфәгатьле башкарма органы, җирле үзидарә органы рәсми рәвештә Дәүләт комитеты һәм җайга салына торган оешма, дәүләт хакимиятенең башкарма органы, җирле үзидарә органы (алга таба - каршылыклар) Карарлар кабул итү регламентында расланган форма буенча каршылыкларны алга таба Каршылыкларны карау комиссиясе утырышында карау өчен Дәүләт комитетына тапшыра.

Каршылыклар Карарлар кабул итү регламентында каралган тәртиптә һәм срокларда Каршылыкларны карау буенча комиссия утырышында карала.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә утырышына чыгарылган карар.

3.6.3. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар Дәүләт комитеты идарәсе утырышында «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең эшчәнлек тәртибен һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышында карау өчен мәсьәләләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2010 елның 26 августындагы 231 номерлы Дәүләт комитеты боерыгында каралган тәртиптә кабул ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бәяләр (тарифлар) билгеләнә торган җайга салу чоры башланачак елның 20 декабреннән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. үзләренә карата элегрәк бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган мөрәҗәгать итүчеләр өчен, шулай ук үзләренә карата элегрәк бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган аерым оешмаларга җылылык белән тәэмин итү өлкәсендәге җайга салынулы аерым эшчәнлек төрләренә бәяләр (тарифлар) билгеләнгән очракта әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза Дәүләт комитетына килгән көннән башлап 30 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт комитеты карары буенча әлеге вакыт 30 календарь көненә озайтылырга мөмкин.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар, Дәүләт комитеты идарәсе утырышы беркетмәсе.»;

5 бүлектә:

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Дәүләт комитетының рәсми сайты, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы, күпфункцияле үзәк аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьләрне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә карала һәм Дәүләт комитетының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 2 нче кушымта

| | |
|---|---|
| Җайга салынулы оешма паспортының типлаштырылган формасы | |
| | |
| Оешманың адресы | |
| Юридик адресы | |
| Почта адресы | |
| Җитәкчесе | |
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Вазыйфа | |
| Фото | |
| Җайга салуның планлаштырылган чоры | |
| Җайга салу чоры | |
| НДС түләүче булып торамы-юкмы | |
| Татарстан Республикасы территориясендә җайга салынулы эшчәнлек алып баручы оешманың (филиалының, аерымланган бүлекчәнең) атамасы | |
| Салым түләүченең тәңгәллек номеры | |
| КПП | |
| Эшчәнлек төре | |
| Оешма гарантияле тәэмин итүче/гарантияле оешма/бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма булып торамы-юкмы | |
| Товарлар төре | |
| Хезмәтләр күрсәтү төрләре | |
| Эшчәнлекнең башка җайга салынулы һәм җайга салынмый торган төрләре булу | |

| | |
|---|---|
| Оешманың гомуми керемендә әлеге төр эшчәнлектән алынган керем өлеше | |
| Расланган инвестиция программасы булу | |
| Документ, инвестиция программасының гамәлдә булу вакыты | |
| Хезмәт күрсәтелә торган муниципаль берәмлек | |
| Коммуналь инфраструктура объектларын эксплуатацияләү нигезе | |
| БМС системасында урнаштырылган Сатып алулар турындагы нигезләмәгә сылтама: | |
| алдагы календарь елда үткәрелгән конкурент сатып алулар саны | |
| алдагы календарь елда үткәрелгән сатып алулар суммасы | |
| Сатып алу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган электрон мәйданчыклар турында мәгълүмат | |
| Документлар тапшыру датасына Монополиягә каршы федераль хезмәтнең 2008 елның 17 апрелендәге 129 номерлы боерыгы нигезендә бер төркем затларга карый торган оешмалар исемлеге | |
| Документлар тапшыру датасына мәшгуль штат берәмлекләре саны»; | |

(белешмәлек) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына

(белешмәлек) кушымта

## Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты

| Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Рәис<br>Груничев Александр Станиславович | 8 (843) 221-82-18 | кt@tatar.ru |
| Рәис урынбасары<br>Павлов Сергей Вячеславович | 8 (843) 221-82-04 | Pavlov.SV@tatar.ru |
| Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге җитәкчесе урынбасары<br>Кубашева Эльза Энгелевна | 8 (843) 221-82-42 | Elza.Kubasheva@tatar.ru |

## Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге башлыгы<br>Салихов Фаил Фатыйх улы | 8 (843) 264-76-02 | Fail.Salihov@tatar.ru |

## Монополиягә каршы федераль хезмәт

Элемтә өчен телефон: 8 (499) 755-23-23, электрон адрес: delo@fas.gov.ru.».